**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАРГАЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЧИСТОПОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КАРГАЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422971, Республика Татарстан,
Чистопольский район, с. Каргали,
ул. Чапаева, 10

422971, Татарстан Республикасы,
Чистай районы, Каргалы авылы,
Чапай урамы, 10

тел: 8(84342) 3-53-66, 3-54-01 e-mail: Karg.Ctp@tatar.ru

***Постановление*** ***Карар***

31.01.2020 ел № 2

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Каргалы авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр хакын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, «Җирләү һәм күмү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында җирләү һәм күмү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары турында»гы 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары белән, Чистай муниципаль районы Каргалы авыл җирлеге Башкарма комитеты

**Карар бирә:**

1. 2020 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Каргалы авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен, 1 нче һәм 2 нче кушымта нигезендә, 6124,86 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. 2020 елның 1 февраленнән “Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Каргалы авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр хакын раслау турында” 2019 елның 30 гыйнварындагы 1/1 номерлы карарны үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольда тотуны үз өстемә алам.

Каргалы
авыл җирлеге башлыгы ___________ М.А. Заһидуллин

Чистай муниципаль районы
Каргалы авыл җирлеге
Башкарма комитетының 2020 елның
31 гыйнварындагы 2 номерлы
Карарына 1 нче кушымта

2020 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Каргалы авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлегенең бәясе

| **Хезмәт күрсәтү исеме** | **Хезмәт күрсәтү бәясе *(сум)*** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү. | 0 |
| 2. Җирләү өчен табут һәм башка кирәк-яраклар бирү һәм китерү. | 4339,17 |
| 3. Мәрхүмнең гәүдәсен (гәүдә калдыкларын) зиратка илтү. | 615,54 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү). | 1170,15 |
| **Барлыгы** | 6124,86 |

Чистай муниципаль
районы
Гаделша авыл җирлеге
Башкарма комитетының 2020 елның
31 гыйнварындагы 2 номерлы
Карарына 2 нче кушымта

2020 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Каргалы авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлегенең бәясе

| **Хезмәт күрсәтү исеме** | **Хезмәт күрсәтү бәясе *(сум)*** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү. | 0 |
| 2. Кәфенләү. | 2171,2 |
| 3. Җирләү өчен табут һәм башка кирәк-яраклар бирү һәм китерү. | 2167,97 |
| 4. Мәрхүмнең гәүдәсен (калдыкларын) зиратка илтү. | 615,54 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү). | 1170,15 |
| **Барлыгы** | 6124,86 |